# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**(IV чакырылыш)**

ундүртенче утырыш

# КАРАРЫ

12 ноябрь 2021 ел **№ 89** Теләче авылы

Татарстан Республикасы Теләче районы төзелүгә 30 ел тулуга багышланган тантаналы чаралар турында

2021 елда Татарстан Республикасы Теләче районы төзелүгә 30 ел тулу уңаеннан, әлеге вакыйгаларның тарихи әһәмиятен исәпкә алып, короновирус пандемиясенә бәйле массакүләм чаралар үткәрү буенча билгеләнгән чикләүләрне үтәү максатыннан, гражданнар, авыл җирлекләре башлыклары, районның иҗтимагый оешмалары, Теләче муниципаль районы Советы мөрәҗәгатьләрен карап, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Президенты Указы белән билгеләнгән даталарга туры китереп 2022 елга , Татарстан Республикасында «Сабантуй» татар халык бәйрәмен уздыру көннәрен Татарстан Республикасы Теләче районы оешуга 30 ел тулуга багышланган тантаналы чаралар үткәрү датасы билгеләргә.
2. Тантаналы чаралар көнен, әлеге карарның 1 пунктын исәпкә алып, Теләче муниципаль районы Башлыгы карары белән билгеләргә.
3. Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, авыл җирлекләре, муниципаль учреждениеләр, предприятиеләр, оешмалар Татарстан Республикасы Теләче районы төзелүгә 30 ел тулуга багышланган тантаналы чаралар планына тиешле үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы

Н.Н. Хаҗипов